

Ләмберә авылынын «Сельхозтехника» микрорайонында «Чиста су» региональ проекты кысаларында ике скважина бораулау һәм 500 метр озынлыктагы магистраль сувткәргеч тозv эшләре бара. Шулай ук жир асты резервуарларын һәм су чистарту станциясен тозv буенча чаралар планлаштырылган.

Региональ проектнын максаты - су белән тәэмин итv һәм су әзерләv системаларын модернизацияләv юлы белән, перспектив технологияләр кулланып, эчә торган сунын сыйфатын арттыру. 2024 елга план буенча, vзәкләштерелгән су белән тәэмин итv системаларыннан сыйфатлы эчәр су белән тәэмин ителгән Мордовия халкы олеше, 2017 елга караганда, 92,5% ка кадәр артырга тиеш.      ГИО «Бурвод» дигән бораулаучылар бригадиры, тумышы белән шул ук районнын Татар Тавласы авылыннан Юнир Мяксум улы Алмакаевка да сусызлык проблемалары билгеле һәм анлаешлы. Анын бригадасы момкин кадәр тизрәк һәм, ин моһиме, кvптән котелгән скважинаны сыйфатлырак бораvларга омтылып, намус белән эшли. Яна елга кадәр эшне тәмамларга тырышалар.